ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИӨИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№12 Бәйрәкәтамак ав. 01 июнь 2018 ел

*Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында*

2017 елның 5 декабрендәге «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү һәм медик - социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 392-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 мартындагы 4 санлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

3.2 пунктының 12 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"- оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыра, шулай ук ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллана һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрүне контрольдә тота;".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында да Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: www.yutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әһлиева

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Для документов
СОВЕТ БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН